СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

26.02.2018 | с. Большие Мени | № 34-159

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 29-133 номерлы Олы Мәми авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Югары Ослан прокурорының 2018 елның 9 гыйнварындагы 02-07-02 номерлы протестын карап, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Мәми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 29-133 номерлы Олы Мәми авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләре (өлешләре) өчен бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә»;

1.2. Әлеге карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүче-физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлау буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы»;

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Мәми авыл җирлеге башлыгы Г.А.Фомина